**СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Ленина, д. 53, с. Ерыклы, 423185

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 53, Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, Zarek.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы ЯңаЧишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“12” нче ноябрь, 2018 нче ел №61-96

**“Татарстан Республикасы ЯңаЧишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 16нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 23-37 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Зирекле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

I. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 16 нче ноябрендәге «Җир салымы турында» гы 23-37 нче номерлы карарына (2017 нче елның 5 нче сентябрендәге 41-64 нче номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 16 нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 23-37 нче номерлы карарының 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Салым ташламалары бирергә:

3.1. шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, гараж һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә җир салымын түләүдән, кануннарда каралган салым

түләүчеләр категорияләреннән тыш, түбәндәге салым түләүчеләргә - физик затлар категориясенә дә азат итү рәвешендә:

- ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнар;
- ятим балалар;
- табигый бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;
- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;
- янгын сагы җәмәгать берләшмәләре һәм ирекле янгын сүндерүчеләр әгъзалары.

Әлеге карарның 3.1пунктында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керә торган һәм Зирекле авыл җирлеге территориясендә берничә җиркишәрлегe (өлешләр) булган физик затларга салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик берҗиркишәрлеге (өлеш) өчен генә бирелә.

3.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

- оешмалар һәм учреждениеләрнең гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата”.

II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын исәпләүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, ләкин рәсми басылып чыкканнан соң бер айдан да иртәрәк түгел.

III. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы” “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә)

IV. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г.Гайфетдинов